Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль
районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем
һәм тәрбия бирү учреждениясе “Шәдче балалар бакчасы”

# Проект

# *Тәрбияле баланың-килəчəге өметле*

Төзеде:
Тәрбияче: Әхәтова Эльмира
Әмир кызы

2020 -2021 ел

Зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркемендә «**Тәрбияле баланың - киләчәге өметле** » темасына проект эше.

**Аңлатма язуы.**

Һәрбер кешегә үзенең төп чыгышы , әби-бабаларының кем булуы, үзенең чын “кече Ватаны” кайда икәнлеген белү бик кызыклыдыр, мөгаен. Мин кайда туган? Беренче карашта бу сорау бик гади тоелса да, чынлыкта исә бик тирән мәгънәгә ия. Үзеңнең тамырларың, нәселең, үткәнең турында кызыксыну – бу һәр кешенең канында булырга тиеш.

Гаиләдә кешенең тормышы башлана, кеше шәхес булып формалаша. Гаиләдәге мөнәсәбәтләр, билгеле булганча, кеше күңеленә гомерлек эз салып калдыра; мәхәббәт дигән олы , бөек хис тә иң беренче нәкъ менә гаиләдә барлыкка килә. Ата-анага мәхәббәт, ихтирам хисе бала тормышында киләчәктә дә , аның алдагы язмышында да мөһим роль уйный. Балаларны туган халкыбызның үткәне, әби-бабаларыбызның гореф-гадәтләре, гаилә шәҗәрәсе, йолалары һәм бүгенге тормыш белән таныштыру зарур. Гаилә шәҗәрәсен алып бару, нәселнең абруе турында кайгырту – тарихи узаң, халкыңа хөрмәт, мәхәббәт тәрбияләүнең бер юлы.

**Проектның актуаллеге.**

Мәктәпкәчә чор – патриотик хисләр, шул исәптән әти-әни, әби-бабай, туганнарга, ягъни гаилә әһелләренә мәхәббәт тәрбияләү өчен иң уңай период булып санала. Шушы чорда иң әһәмиятле әхлакый сыйфатлар формалаша. Зурлар, мәктәпкә әзерлек төркемендә балаларның гаилә турында киң күзаллаулары . Балалар, гаиләләре турында беләләр: мәсәлән, “әни” һәм “әнинең исеме”, “әти”, “әтиеңнең исеме” төшенчәләрен аералар, әти-әниләренең кайда эшләүләрен, әби-бабайларының кем булуын беләләр, туганлык мөнәсәбәтләрен – кем олы, кем кече икәнен барысы да төгәл аңлатып бирә алмыйлар.

Әлеге проект – гаиләнең кеше тормышындагы роле турында уйланырга мәҗбүр итүче искиткеч сәбәп булып тора. Проект буенча эшләү баланың шәхес булып үсүенә зур йогынты ясый, балаларда үзләре турында кайгыртучы туганнарына карата уңай мөнәсәбәт формалаштырырга ярдәм итә.

**Проектның максаты:** балаларга гаилә турында төшенчә бирү, әти-әниләренә, туганнарына карата ярату, хөрмәт итү, үзара аңлашып яшәү хисе тәрбияләү.

**Бурычлары:** балаларны “гаилә”, “исем”, “фамилия” төшенчәләрен аңлап әйтеп бирүгә ирешү; балаларның әти-әниләре, туганнары турындагы белемнәрен ачыклау; балалар, әти-әниләр, туганнар арасында яхшы мөнәсәбәтләр булдыруга юнәлтелгән шартлар тудыру; ата-аналарда балалар белән актив рәвештә бердәм эшчәнлек алып барырга омтылыш уяту; балаларның аралашу, коммуникатив осталыкларын устерү.

**Көтелгән нәтиҗәләр: б**алалар үз туганнары турында күбрәк беләчәкләр.Балалар һәм әти – әниләр арасындагы якынлык тагы да ныгытыла, алар бер-берсенә карата уңай мөнәсәбәттә булачаклар. Балалар гаилә әгъзалары арасындагы туганлык мөнәсәбәтләрен дөрес итеп әйтергә

өйрәнәчәкләр. Ата – аналарда балалар бакчасы белән үзара мөнәсәбәтләрне дәвам итү теләге барлыкка киләчәк.

**Проектта катнашучылар:** балалар, тәрбияче, ата-аналар.

**Проект дәвамлыгы:** 9 ай.

**Проектны оештыру формасы**:

1. Балалардан сорау-җавап алу.
2. Белем бирү эшчәнлеге.
3. Сюжетлы-рольле һәм дидактик уеннар.
4. Балалар эшләреннән күргәзмә оештыру.
5. Әти-әниләр өчен консультацияләр.
6. Фотокүргәзмә.
7. Альбом ясау.
8. Ата-аналар җыелышы.
9. Ата-аналардан анкета алу.

**Җиһазлау:** компьютер, магнитофон, фотоаппарат, мультимедиа, уеннар өчен атрибутлар, күрсәтмә материаллар.

**Проектны тормышка ашыру этаплары:**

I этап – әзерлек:

1. Балалардан сорау-җавап алу.
2. Ата-аналардан анкета алу.
3. Максат һәм бурычларны билгеләү.
4. Проектны тормышка ашыру өчен уңай мөһит булдыру.

II этап – төп (практик) этап:

1. Балаларның гаилә турында белемнәрен арттыру максатында тәрбия һәм белем бирү эшендә эффектив ысуллар һәм алымнар куллану.
2. Ата-аналар өчен консультацияләр әзерләү: “ 5-7 яшьлек балаларның яшь үзенчәлекләре”, “Баланың гаиләдәге урыны”, “ Дидактик уеннарның роле”, “Гаилә тәрбиясендә ялгышлар”,”Гаиләдә ата тәрбиясе”
3. Күргәзмәләр оештыру: “ Безнең бакча уңышы”, “Алтын куллы әнием”, “Ир кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз”.
4. Фотокүргәзмәләр оештыру: “Минем гаиләм”, “Минем әби-бабайларым”, “Әнием – иң якыным”, “Оста куллы әтием”.
5. Балалар эшләре буенча күргәзмә оештыру: “Минем гаиләм”, “Кадерле әнием”
6. Бәйрәм иртәләре оештыру :“Әтиләр бәйрәме” ,“Әнием – иң кадерлем, син, минем”
7. Әти-әниләр һәм балалар белән берлектә сюжетлы-рольле уеннар өчен атрибутлар әзерләү.
8. Тема буенча тәкъдимнәр , методик материаллар туплау.

III этап – йомгаклау:

1. Проектны тормышка ашыру буенча нәтиҗәләр чыгару.
2. “Гаиләдән дә кадерлерәк нәрсә бар?” темасына ата-аналар җыелышы уздыру.
3. Ата-аналар һәм балалар белән берлектә гаилә шәҗәрәсен ясау.

**Проектны тормышка ашыру планы**.

| Этаплар | Эшчәнлек әчтәлеге | Үтәлү вакыты |
|---|---|---|
| I этап.<br>Әзерлек этабы. | Балалардан сорашу. “Нәрсә ул гаилә?”<br>Ата-аналардан анкета алу.<br>Проектны тормышка ашыру өчен план төзү. | сентябрь |
| II этап.<br>Төп (практик) этап. | Коммуникация, матур әдәбият белән таныштыру.<br>Әти-әни, туганнар турында шигырьләр, матур әдәбият уку:Ә.Бикчәнтәева “Бәтиләр”, Ш.Маннур “Яратам” ,“Кем нәрсә ярата” татар халык әкияте , “Әлли-бәлли итәргә...” бишек җыры,“Өч кыз” татар халык әкияте, З.Туфайлова “ Шофер булам” , Д.Аппакова “Рөстәм”, З.Туфайлова “Әни сүзе”, Г.Нәбиуллина “Әнигә булышам” ,Л.Толсткой “Өч аю”<br><br>Танып – белү өлкәсе<br>“Әбием үстергән көзге уңышлар”<br>“Кунак каршылыйбыз”<br>“Безнең кунаклар” мультфильм карау<br>“Кояш гомере телим мин,әнием сиңа!” әңгәмә<br>“Минем әнием” әңгәмә<br>Балаларны “ Минем өем” төшенчәсе белән таныштыру.<br>“Минем әтием” әңгәмә<br>“Әтием солдат булган”<br>“ 8 март – әни бәйрәме” әңгәмә<br>“Әбием, бабаем  - минем горурлыгым” әңгәмә.<br><br>Төзү.<br>“Әбиемнең каз бәбкәләренә читлек төзү”<br>“Безнең матур, төзек өй”<br>“Бабама булышам – өйләр һәм кечкенә коймалар”<br>“Әтиемә гараж”<br><br>Рәсем иҗаты<br>“Әбиемә төсле җепләр”<br>“Әниемә матур шарлар”<br>“Әбиемә матур кулмәк” | сентябрь –май<br><br>сентябрь<br>октябрь<br>октябрь<br>ноябрь<br>ноябрь<br>декабрь<br>январь<br>февраль<br>март<br>апрель<br>май<br><br>октябрь<br>ноябрь<br>декабрь<br>февраль<br><br>сентябрь<br>октябрь<br>ноябрь<br>декабрь<br>январь<br>март<br>апрель<br>май |

| | | |
|---|---|---|
| | “Әтиемә төсле тәгәрмәчләр” | октябрь |
| | “Безнең чыршы” | ноябрь |
| | “Әниемә тәлинкә” | ноябрь |
| | “Яңа телевизор” | декабрь |
| | “Әбиемә матур яулык” | февраль |
| | | март |
| | Әвәләү | |
| | “Әниемә тәмле крэндилләр” | |
| | “Әбиемнең туган көненә күчтәнәч” | ноябрь |
| | “Әтиемә тәмле алмалар” | декабрь |
| | “Әбиемнең зур, кечкенә коймаклары” | январь |
| | “Бабаема бүләк – самолет” | март |
| | “Әниемә теләгән бүләгемне әвәләү” | май |
| | Кисеп-ябыштыру. | |
| | “Әниемә төрле төстәге палас” | сентябрь – май |
| | “Әтиемә җылы шарф” | |
| | “Әбиемә алъяпкыч бизәү” | |
| | “Бабаема - түбәтәй” | |
| | Җырлар өйрәнү. | сентябрь - май |
| | “Без яулыклар юабыз. С.Сабирова | |
| | “Кояшлы җыр” М.Шәмсетдинова | |
| | “Мамина улыбка” Ж. Цыбров | |
| | “Әбием, әбекәй” Г. Ахметова | |
| | Иллюстрацияләр күзәтү. | |
| | “Гаилә”, “Тавык һәм чебиләр”, “Әтиемнең эшендә” | сентябрь – май |
| | “Әнием – пешекче”, “Әнием - кибетче” | сентябрь – май |
| | “Гаиләм турында нәрсә беләм?” сорау-җавап | сентябрь - май |
| | Гаилә фотоальбомын күзәтү | |
| | Дидактик уеннар | |
| | “Кем булырга” | |
| | “Рәсемне төзе” | |
| | “Дәвам ит” | |
| | “Кем олырак, кем кечерәк?” | |
| | “Белмәмешкә ярдәм ит” | |
| | “Туганлык мөнәсәбәтләре” | сентябрь – май |
| | “Өйдә сиңа ягымлы итеп ничек эндәшәләр?” | |

| | | |
|---|---|---|
| | Сюжетлы-рольле уеннар<br>“Гаилә”, “Шифаханә”, “Шофер” ,<br>“Курчакны йоклатабыз”, “Чәй әзерлибез”,<br>“Кибет”.<br><br>Әңгәмә оештыру.<br>“Минем гаиләм”<br>“Өйдә куркынычсызлык кагыйдәләрен<br>үтәү”<br>“Гаиләдә мин ничек булышам”<br>“Әти-әниләрең кем булып эшли?”<br>(фотоальбом куллану)<br>“Гаилә белән  ничек ял итәбез?”<br><br>Әкиятләр сәхнәләштерү<br>“Шалкан “, “Чаур тавык”, “Өч кыз”<br><br>Ата-аналар өчен консультацияләр<br>“ 4-5”, “5-6” яшьлек балаларның яшь<br>үзенчәлекләре”,<br>“Баланың  гаиләдәге урыны”<br>“Дидактик уеннарның роле”<br>“Гаилә тәрбиясендә ялгышлар”<br>“Гаиләдә ата тәрбиясе”<br><br>Күргәзмә оештыру.<br>“Безнең бакча уңышы”<br>“Алтын куллы әнием”<br>“Ир кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз”.<br><br><br>Фотокүргәзмә оештыру.<br>“Минем гаиләм”<br>“Минем әби -бабайларым”<br>“Оста куллы әтием”.<br>“Әнием – иң якыным”<br><br>Балалар эшләре буенча күргәзмә.<br><br>“Минем гаиләм”. “Кадерле әнием”<br><br>Ата-аналар җыелышы<br>“Әхлакый сыйфатлар тәрбияләүдә<br>гаиләнең роле” | ноябрь<br>декабрь<br>январь<br>март<br>апрель<br><br><br>сентябрь - май<br><br>сентябрь<br>ноябрь<br>декабрь<br>январь<br>март<br><br><br>сентябрь<br>ноябрь, март<br>февраль<br><br><br><br>ноябрь<br>январь<br>февраль<br>март<br><br><br><br>ноябрь<br>март<br><br><br>декабрь<br><br><br>февраль<br><br><br><br><br><br><br><br>март |

| | | |
|---|---|---|
| | Бәйрәм иртәләре оештыру<br>“Әти, әткәй - әтием бәйрәме”<br>“Әнием – энҗе бөртегем” | |
| III этап<br>Йомгаклау | Ата-аналар җыелышы<br>“Безнең уңышлар. Гаиләдән дә кадерлерәк нәрсә бар?” | май |
| | Балалар белән әңгәмә<br>“Нәрсә ул гаилә?” | май |
| | “Безнең гаилә – татау гаилә”. Балалар һәм әти – әниләр катнашында бәйге. | май |
| | Методик продукт: “Минем гаиләм”проектын презентацияләү. Гаилә шәҗәрәләре. | май |

***Кушымта.***

*( Зурлар, мәктәпкә әзерлек төркеме балалары өчен “Гаилә көне”нә багышланган бәйге).*

**Эшчәнлек барышы**

***Гаилә бәйрәме зурлар, мәктәпкә әзерлек төркеменә йөрүче балалар, аларның әти – әниләре, тәрбияче катнашында үткәрелә.***

**Катнашалар: тәрбияче, әти – әниләр , балалар.**

Зал бәйрәмчә бизәлә. Түрдәге стенага **“Безнең гаилә – тату гаилә ”** дип язылган плакат эленә.Шарлар, чәчәкләр, ак күгәрченнәр эленә. Катнашучы гаиләләр санынча өстәлләр куела, ә өстәлләрдә – гаиләләрнең эмблемасы һәм исем – фамилияләре язылган табличкалар. Балалар һәм кунаклар залга кергәндә аудиоязмада *“Хәерле көн” җыры* (А. Минһаҗев сүзләре, Ә. Һадиева көе) яңгырый, балалар кушылып җырлыйлар.

Йокыдан уянуга, мин
Беләм,нишләргә кирәк:
Елмаям, әти – әнигә,
Хәерле көннәр теләп.

Хәерле көн күршеләргә,
Дуслар, туганнарга да.
Теләктән читтә калмасын
Таныш булмаганнар да.

Кушымта:
Яратам мин, яратам шул
Матур теләк теләргә.
Онытты, дип уйламагыз,
Хәерле көн сезгә дә!

**Тәрбияче.** Хәерле көн, кадерле балалар, хөрмәтле әти – әниләр һәм бәйрәмгә килгән барлык кунаклар! Балачак чоры - кабатланмас, тылсымлы дөнья. Безнең нәниләребез өчен ул - Шәдче балалар бакчасы. Бу серле дөньяда тормышыбызны дәвам итүчеләр, киләчәк буын тернәкләнә.

Әлбәттә, без - тәрбиячеләрнең төп максаты балаларга дөрес тәрбия бирү, аларны сау-сәламәт итеп үстерү. Ана теленә, халкыбызның гореф-гадәтләренә мәхәббәт тәрбияләү. Бүген без сезнең белән - гаилә бәйрәменә җыелдык. Гаилә - ул иң олы таянычыбыз, иң ышанычлы сыеныр урыныбыз. Анда бер-берсен яраткан, бер-берсе турында кайгыртучанлык күрсәткән кешеләр яши.

Гаилә баланың төп ярдәмчесе. Һәр гаиләнең үзенә генә хас юллары, тәрбия алымнары бар. Гаилә – тормышыбызның нигезе, дәүләтнең киләчәге. Матур гаилә корып, бер – береңне хөрмәтләп, бер – береңә ярдәмләшеп яшәү- һәрберебезнең изге бурычы. Безнең бүгенге бәйрәмебез дә юкка гына **“Безнең гаилә – тату гаилә”** дип аталмый. Тату гаиләләрдә генә тырыш, уңган, тәүфыйклы, акыллы балалар үсә. Менә шундый күркәм сыйфатлары булган гаиләләр бүген бездә кунакта. Хәзер бәйрәмебез түренә аларны чакырабыз. Рәхим итегез, хөрмәтле әти – әниләр!

( *Тәрбияче аларның һәрберсе белән таныштырып чыга.)*

**Зөһрә:**
Бәйрәмсез бик күңелсез бит,
Күңелсездер сезгә дә
Бәйрәмнәр кирәк безгә дә,
Бәйрәмнәр кирәк сезгә дә.
Кирәк һәммәбезгә дә!

**Камилә.**
Бик күп илләр сүз беркетеп
Бирешеп кулга – кулны,
Әйткәннәр: “ Майнын унбише =
Булсын ул – “Гаилә көне!”.
“Гаилә дигәч, кем уйламас

Әти - әни турында?
Шулай булгач, бүгенге көн
Ул әниләр көне дә!
Ул – этиләр көне дә!
Ул – сабыйлар көне дә!
**Салават:**
Бүген - гаилә бәйрәме,
Бүген бездә тантана.
Кояш шуңа көлә бүген,
Гөлләр шуңа шатлана.
**Гүзәл:**
Без бәйрәмнәр яратабыз,
Бәйрәм көннәр еш булсын.
Әти – әни һәм кунаклар
Безгә гел килеп торсын.
**Барысы бергә.**
Бәйрәмнәр булып торсын!
Бәйрәмнәр гөрләп торсын!

***(Балалар үз әти – әниләре янына, өстәл артына барып басалар)***

**Тәрбияче.** Бәйрәмнәр бик күп. Ә гаилә бәйрәменең иң тәүгесе кайсы икән? *(Никахлашу көне)* , (*Туй көне*.) Әйе, бер – берсен яраткан яшь егет белән кыз никахлашып, гаилә корып җибәрә. Гаилә нык, имин булсын өчен аның үз законнары, кануннары барлыкка килә. Алар үзләре дә сизмәстән шушы кануннар нигезендә яши башлый. Ул кануннарны без гаиләнең девизы дип атадык. Кайсы гаилә нинди девиз нигезендә яши икән?

**I бәйге. “Гаилә девизы”**

***Һәр гаилә үз девизын әйтә***, мәсәлән:
1.“Иңне – иңнәргә терәп,
Әби – бабайга кирәк
Балаларга без терәк
Булып яшәргә кирәк.”
2.“Картайганчы, тигезлектә
Бергә тормыш көтәргә.
Кайгыны да, шатлыкны да
Һәрчак уртак итәргә!”
3.“Алдашмаска, адашмаска,
Авырлыкта – ташлашмаска!” һ. б.

**Тәрбияче.** Әйе, шундый девизларга таянып яшәгән гаиләләр чынлап та күркәм була. Ә инде дөньяга уртак бала тугач, бу гаилә тагын да матурланып, тулыланып китә. Сабый дөньяга аваз салганчы ук, әти – әнисе аңа исем сайлый. Һәр исем нинди дә булса бер мәгънәгә ия. Безнең гаиләләр балаларының исемнәре нәрсә аңлатканын беләмикән?

**II бәйге. "Балагызның исеме нәрсәне аңлата?" (*Һәр гаилә үз баласы исеменең мәгънәсен аңлата, мәсәлән: Булат – корыч кебек нык, таза, Камил – тулы, бөтен. Зөһрә — нур чәчеп, балкып торучы, чәчәк, Зөһрә йолдызы, Чулпан, Венера, Гүзәл — бик матур, гүзәллек иясе, Камилә — тулы, бөтен, һәрьяктан җитешкән, Салават — догалар, мактау һ.б.)***

**Тәрбияче.** Бала тугач та гаиләнең иң кадерле кешесенә әйләнә, ул гаиләне тагын да ныгыта, дуслаштыра. Әти кеше, ир – ат буларак, бала тугач бөтен авырлыкны үз өстенә алырга тырыша. Кайсы әти күбрәк булышты икән? Сынап карыйк әле!

**III бәйге. "Кайсы әти баланы тизрәк биләүләп әнисенә тапшыра".**

*( Әтиләргә курчаклар һәм биләүлекләр бирелә. Алар курчакны тиз генә төреп әниләргә тапшыра.)*

**Тәрбияче.** Ә хәзер чират әниләргә җитте. Бар йөрәкнең җылысын, назын алар бишек җырларына салган. Әниләребез балаларына нинди бишек җырларын җырлады икән?

**IV бәйге. " Бишек җырлары".** (*Һәр ана баласына җырлаган бишек җырын башкара.)*

**Тәрбияче.** Бала үсеп, тәүге адымнарын ясаганда, беренче сүзләрен әйткәндә, алар белән бик кызык хәлләр булгалый. Һәр гаиләнең күңел түрендә нинди дә булса кызыклы хәл саклангандыр. Шуларны искә төшерик әле.

**V бәйге. " Бала белән булган кызыклы хәл" .**

(*Һәр гаилә баласы белән булган нинди дә булса кызыклы вакыйганы искә төшереп сөйли.)*

**Тәрбияче.** Гаиләнең ныклыгы, татулыгы күп нәрсәләргә бәйле. Хәзер мин сезгә шуның берсе турында әйтәм:

Кайвакыт ул мамык төсле йомшак,
Кайвакытта корычтай ул каты.
Кайчагында була баллы, татлы,
Ә кайчагында әремнән дә әче.
Бу нәрсә?

- Әйе, тел. Тел – ананың балага биргән иң кадерле бүләге. Ә сез гаиләдә матур итеп сөйләшә, бер – берегезгә тәмле сүзләр әйтә беләсезме икән, сынап карыйк әле!

**VI бәйге. “ Кайсы гаилә күбрәк матур сүзләр белә?”** (*Һәр гаилә чиратлап матур сүзләр әйтә, мәсәлән: 1 нче гаилә: “Матурым” , - ди. 2 нчесе – “Акыллым”. 3 нчесе “Йомшагым”, ди. Ахыргы гаилә матур сүз әйткәннән соң, 1 нче гаилә һәм башка гаиләләр уенны дәвам итәләр. Сүз таба алмыйча туктап калган гаилә уеннан “төшеп кала”.)*

**Тәрбияче.** Гаилә – үзенә күрә кечкенә генә бер дәүләт. Ул дәүләтнең президенты да, финанс министры да бар. Балалардан сорыйк әле: Сезнең гаиләдә кем баш? Ни өчен шулай уйлыйсың? Гаиләдә акчаны кем саный? Кем күбрәк “туздыра”?

**VII бәйге. “Кайсы гаилә күбрәк акча эшли?” (*Идәнгә вак акчалар сибелә. Әтиләр – җыя, балалары – ташып тора, әниләре – саный.)***

**Тәрбияче**.Барыбыз да беләбез, бала үскәндә акчаның күпмедер өлеше уенчыклар алуга тотыла. Әти – әниләр балаларына нинди уенчык кирәк икәнен беләме?

**VIII бәйге. “ Күз бәйләп кем тизрәк уенчык сайлый?” ( *Һәр әни, күзләрен бәйләп, “Уенчыклар кибете”ннән баласы әйткән уенчыкны капшап таба һәм аңа тапшыра.)***

**Тәрбияче.** Уенчыклар белән уйнап бала үсә, бакчага йөри, ә кичләрен гаилә әгъзалары бергәләп ял итәләр, күңел ачалар. Кайсы гаилә ничек ял итә соң?

**IX бәйге “ Гаиләләрнең концерт номерлары”** ***( Һәр гаилә үз талантын күрсәтә.)***

**X бәйге. “ Кем ачкычны тизрәк таба?” ( *Әниләргә йозаклар һәм ачкыч бәйләмнәре бирелә. Кайсы әни йозакка тиешле ачкычны тизрәк таба, шул җиңүче була.)***

**Тәрбияче**: Иң житез хуҗабикәне инде белдек. Әле бит хуҗаның да булдыклы, ярдәмчел булуы кирәк. Аларны да сыныйк әле. ( *Балаларның киемнәренә кер каптыргычлары кыстырып чыга.*) Караңгыда кайсы әти аларны тизрәк табар икән?

**XI бәйге. “ Күз бәйләп кер каптыргычларын эзләү”.**

**XII бәйге. “Милли ашларны яхшы беләсезме?”(*Сорауларга җаваплар бирү*.)**

-Геометрик фигураны эченә алган милли ризык? (*Өчпочмак.*)

-Катлы – катлы татлы бәлеш? (*Гөбәдия.)*

-Туй табынының иң түрендә? (*Чәк – чәк.*)

-Ике сүздән торган милли ризык? (*Кош* теле.)

-Камырдан пешерелгән аш? (*Токмачлы аш.)*

-Эченә бәрәңге боламыгы салып пешерелгән ризык? (*Кыстыбый.*)

-Көн саен кирәкле ризык. Аннан башка аш үтми, аңа халык дан җырлый. (*Икмәк.*)

**XIII бәйге. "Мәкальнең ахырын әйт!"**

-Кем эшләми... (*шул ашамый.*)

-Беләге юан берне егар ... (*белеме булган меңне егар.)*

-Һөнәрле үлмәс ... ( *һөнәрсез көн күрмәс.*)

-Казаныңа ни салсаң ... (*кашыгыңа шул чыгар.*)

-Ана күңеле балада ... (*бала күңеле далада.*)

-Ата – ананы тыңлаган адәм булган ... (*тыңламаган әрәм булган.)*

-Атасына карап ... (*баласын коч.*)

-Оясында ни күрсә ...(*очканда шул булыр.*)

-Ата – анасына игелек күрсәтмәгән, олыгайгач үзе дә ... (*игелек күрмәс.*)

-Үзеңне үзең мактама ... (*кеше сине мактасын.*)

-Игелекле бала үстерсәң ... (*картлыгың бәхетле булыр.*)

**Тәрбияче.**Ә хәзер, хөкемдарлар бәйгеләргә нәтиҗә ясаган арада, сүзне балаларга бирик.

**Азалия.**

Безнең төркем балалары –
Әйтерсең бер гаилә.
Дус, тату, бердәм яшибез,
Күреп торасыз менә.

**Зөһрә.**

Күп белергә омтылабыз,
Матур җырлар җырлыйбыз.
Бию көе яңгыраса,
Ялындырып тормыйбыз.

**("*Без биибез" дигән көйгә ( Р. Гатауллин көе) җырлы бию башкарыла***

**Тәрбияче**. Бәйрәмебез ахырына якынлаша. Безнең әти – әниләргә, әби – бабайларга әйтер сүзебез бар. Бу нәниләр – безнең киләчәгебез. Аларны яратыгыз, мәрхәмәтле, тәүфыйклы итеп үстерергә тырышыгыз! "Тәүфыйклы бала – бәхетле бала" дип, борынгылар юкка әйтмәгән. Ә балаларыбызга бәхетле булу өчен тагын нәрсә кирәк икән?

| **Тәрбияче** (*балалардан сорый*) | **Балалар**(*барсы бергә*): |
|---|---|
| -Җирдә сезгә ни кирәк? | - Әти һәм әни кирәк. |
| -Җирдә сезгә ни кирәк? | - Без яшәрдәй өй кирәк. |
| -Җирдә сездә ни кирәк? | - Туган үскән ил кирәк. |

-Җирдә сезгә ни кирәк? - Туган телебез кирәк.

**Тәрбияче.** Әйе, хөрмәтле әти – әниләр, балаларыбыз дөрес әйтә. Туган теле булган халыкның гына киләчәге бар. Шуны онытмасак иде. Хөкемдарлар нәтиҗә ясаган арада туган телебезгә мәдхия җырлап алсак, бәйрәмебез тагын да ямьләнеп китәр.

***Барысы бергә басып " Туган тел" җырын башкарганнан һәм***

***Нәтиҗәләр ясалганнан соң, гаиләләргә "Иң зыялы гаилә", "Иң күркәм гаилә", "Иң креатив гаилә"***

***"Иң тырыш.." һ.б. шундый номинацияләр бирелә, бүләкләр тапшырыла.***

**Тәрбияче.** Безнең "Гаилә көненә" багышланган бәйгебез тәмам. Бик зур рәхмәт сезгә - хөрмәтле әти – әниләр, балаларыбызга һәм алар өчен җан атып утырган әби - бабайларга! Сау булыгыз! Киләсе очрашуларга кадәр!

Кулланылган әдәбият:

1.Веракс Н.Е "От рождения до школы" программасы
2.Закирова К.В. "Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе"
3.Мирзахова Н.Р. "Мин бәхетле гаиләм белән".
4.Зарипова З.М. һ.б."Туган телдә сөйләшәбез" .
5. Татар халык мәкальләре җыентыгы